| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЬМЕТЬЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘЛМӘТ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» мая 2026 ел г. Альметьевск № 842

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы (Әлмәт шәһәре) үзәгеннән 11 километр ераклыкта урнашкан Әлмәт муниципаль районының авыл торак пунктларына беренче кирәк-ярак товарларын китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнары өлешен каплауга Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе турында» 2024 елның 14 августындагы 2664 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендәге грантлар, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, физик затларга һәм күрсәтелгән субсидияләрне алучыларны, шул исәптән субсидияләр рәвешендәге грантларны сайлап алуны җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары нигезендә, кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы (Әлмәт шәһәре) үзәгеннән 11 километр ераклыкта урнашкан Әлмәт муниципаль районының авыл торак пунктларына беренче кирәк-ярак товарларын китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнары өлешен каплауга Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе турында» 2024 елның 14 августындагы 2664 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 22 июлендәге 1772 номерлы, 2025 елның 19 декабрендәге 2949 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- карар преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

заказ № 4553-940

«Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендәге грантлар бирүне һәм күрсәтелгән субсидияләрне алучыларны сайлап алуны җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, «Куллланучылар кооперациясе оешмаларының Татарстан Республикасы район үзәкләреннән 11 километр ераклыкта урнашкан авыл торак пунктларына беренче кирәк-ярак товарларын илтеп җиткерүгә бәйле чыгымнары өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансферлар бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 20 ноябрендәге 887 номерлы карарын үтәү йөзеннән;

- карарга 1 нче кушымтаның 1.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидияләр, шул исәптән район бюджеты турындагы карарда (район бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү турындагы карарда) каралганнары турындагы мәгълүмат "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба - бердәм портал) Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә субсидияләр бирүгә бюджет ассигнованиеләрен бюджет акчаларын баш бүлүчегә җиткергән көннең иртәгесеннән 10 эш көне эчендә урнаштырыла.»

- карарга 1 нче кушымтаның 2 бүлегендәге 2.1 пунктының унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкчеләр, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер кеше кулындагы башкарма орган функцияләрен башкаручы зат турында, яисә юридик зат булган субсидия алучының (сайлап алуда катнашучының) баш бухгалтеры (булган очракта) турында, субсидия алучы (сайлап алуда катнашучылар)индивидуаль эшкуар, физик зат турында мәгълүматлар юк.»;

- карарга 1 нче кушымтаның 3.1, 3.2 пунктларында «сәүдә, куллланучылар хезмәтләре күрсәтү һәм эшкуарлыкны үстерү бүлеге» сүзләрен «инвестицион үсеш һәм эшкуарлык бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.»;

карарга 1 нче кушымтаның 3.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия район Башкарма комитеты тарафыннан субсидияләр алучылар тарафыннан Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында ачылган счетларга бюджет акчаларын баш бүлүче тарафыннан 3 бүлегенең 3.1 пунктында күрсәтелгән документларны карау һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча субсидия бирү турында Карар кабул ителгән көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча 10 нчы эш көненнән дә соңга калмыйча күчерелә.»

- тәртипкә 3 нче кушымтада:

Насыйров А. Б. вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының инвестицион үсеш һәм эшкуарлык бүлеге башлыгы;».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Ә. Ямалетдиновка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов